**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның «29» декабреннән № 5-31

2026 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А. Тарнавский

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Советының
2025 елның 29 декабрендәге
5-31 номерлы карарына
кушымта

2026 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы)

1. Гомуми нигезләмәләр

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2016 елның 28 июнендәге 15-59 номерлы карары белән расланган Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милкен биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә 2026 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль районын хосусыйлаштыруның фаразлау планы (алга таба - Фараз планы) эшләнде.

2. 2026 елда ачык аукционнарда сату юлы белән хосусыйлаштырылырга тиешле Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм мөлкәтләр исемлеге

| №т/б | Муниципаль милек исеме | Урнашу урыны | Мәйдан, кв. м. | Хосусыйлаштыруның планлаштырылган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Җиңел автомобиль FORD MONDEO 212300-55, д/н Х 435 РЕ 116 RUS, 2016 елда чыгарылган, VIN Z6FDXEEECDG201 | ТР, Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Ленин ур., 37 А й. | - | 2026 елның 1 кварталы |
| 2 | Белем бирү корпусының торак булмаган бинасы, кадастр номеры 16:31:150106:131, гомуми мәйданы 190,5 кв.м. һәм кадастр номеры 16:31:150106:397 булган, гомуми мәйданы 160 кв.м., адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Парк урамы, 12 йорт. | ТР, Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Парк ур., 12 | 190,5 | 2026 елның 1 кварталы |
| 3 | Җиңел автомобиль LADA NIVA 212300-80 д/н К825СУ 716 RUS, 2021 елда чыгарылган, VIN ХТА212300N0805598 | ТР, Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Ленин ур., 37 А й. | - | 2026 елның 1 кварталы |